Әkhmət'yanov, R. G. (2015). *Tatar teleneң etimologik syzlege* [Etimology of Words in the Tatar Language]. T. I: А–Л. 543 p. T. 2: М–Я. 567 p. Kazan, Məgarif–Vakyt. (In Tatar)

---

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНДӘ ЛЕКСИК ИНТЕРФЕРЕНЦИЯ КҮРЕНЕШЕ

**Гөлшат Рәис кызы Галиуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
Gulshat.Galiullina@ksu.ru.

Мәкаләдә хәзерге татар сөйләм теленә хас лексик интерференция күренеше өйрәнелә. Төп игътибар сөйләм телендә киң таралыш тапкан лексик берәмлекләрнең функциональ мөмкинлекләре, таралыш даирәсенә юнәлә. Фактик материалны төрле яшьтәге һәм социаль статустагы татар кешеләренең алдан әзерләнмәгән спонтан сөйләме теркәлгән 120 аудиоязма тәшкил итә. Шулай ук, нәтиҗәләрне нигезләү өчен, «Татар теленең язма корпусы», «Татар матур әдәбияты корпусы» материаллары да карала.

Анализ күрсәткәнчә, хәзерге татар сөйләм теленә хас интерференциянең сәбәпләре лингвистик шартларга гына түгел, психологик һәм социомәдәни факторларга да турыдан-туры бәйләнгән. Татар телендә эквивалентлары булуга карамастан, башка тел сүзләрен куллану лексик интерференциянең системалы, татар телендә сөйләшүчеләр өчен гадәти күренеш икәнлеге, билингваль шартларда ике тел лексикасын янәшә куллануда чикләр җуела баруы күренә.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, сөйләм теле, билингвизм, интерференция, лексика, лексик интерференция.

Хезмәт № 17-14-16012 фәнни проект кысасында РФФИ һәм Татарстан Республикасының финанс ярдәме белән башкарылды.

Сөйләм теле кешелек җәмгыятендә гаять әһәмиятле урын били. Аның төп вазифасы – кешеләрнең көндәлек аралашуын тәэмин итү. Кодификацияләнгән әдәби телдән аермалы

буларак, ул барлыккка килүе һәм кулланылышы ягыннан беренчел санала. Шунлыктан телдә барлыкка килгән һәртөрле үзгәреш һәм яңалык, беренче чиратта, сөйләм телендә урын ала. Соңрак әлеге яңалыклар, вакыт һәм халык тарафыннан сайлау сынавын үтеп, кодификацияләнгән әдәби телгә үтеп керә ала.

Сөйләм теле, әдәби нормаларның тиешенчә сакланмавы һәм гомумкулланылыштагы сүзләрнең күп булуыннан тыш, үз эченә иҗтимагый һәм территориаль диалектларны, гади сөйләм элементларын алу белән аерылып тора. Моннан кала, сөйләм теленең үзенә генә хас лексик-семантик, фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре булуын һәм сөйләм телендә кулланыла торган берәмлекләрнең үзара ярашу мөмкинлекләре үзгә икәнен дә искәртү зарур. Болар, үз чиратында, сөйләм теленең мөстәкыйль системага хас статусы булуына ишарә итә.

Әлеге мәкаләдә без шундый үзенчәлекләрнең берсен – хәзерге сөйләм теленә хас лексик интерференция күренешен өйрәнүне максат итеп куябыз.

Өйрәнү объекты итеп сөйләм телендә киң таралыш тапкан кайбер берәмлекләрнең функциональ үзенчәлекләре, таралыш даирәсе алынды.

Чыганак буларак хәзерге татар сөйләме үрнәкләрен туплаган 120 аудиоязма алынды. Аларда Татарстан Республикасының төрле районнарында яшәүче 18–25 һәм 30–50 яшьтәге социаль статуслары, белем дәрәҗәләре төрле татар теле вәкилләренең көнкүрешнең төрле өлкәләренә караган диалогик формадагы алдан әзерләнмәгән спонтан сөйләме теркәлгән. Респондентларның сөйләмен яшьләр һәм урта яшьләрдәге тел вәкилләренә бүлү телдә типик саналган, инде киң таралыш тапкан һәм сөйләм теленең аерым бер үзенчәлекле ягы буларак саналырга хаклы лексик үзенчәлекләрнең асылын һәм кулланылыш тирәнлеген ачыклау өчен кирәк булды.

Аерым очракларда «Татар теленең язма корпусы» материалларына да мөрәҗәгать ителде.

Өйрәнү объектына бу рәвешле якын килү лексик интерференция күренешенең таралыш даирәсен, телдә урнашу дәрәҗәсен ачыклау өчен кирәк дип табылды. Шуны ассызыклау урынлы булыр: татар сөйләм теле – экстра- һәм интралингвистик чаралар тәэсирендә даими үсеп-үзгәреп торган система. Сөйләм телендә барлыкка килгән аерым үзенчәлекләр, киң таралыш табу сәбәпле, соңрак кодификацияләнгән әдәби телгә үтеп кереп, тел нормасына әйләнергә мөмкин, бу исә, үз чиратында, милли телнең сыйфат ягыннан үзгәрешенә китерә. Шунлыктан телнең эчке үсеш-үзгәреш юнәлешләрен күзаллау өчен сөйләм телен даими өйрәнү аеруча зарур.

Гомумән алганда, татар тел белемендә сөйләм теленең өйрәнелү тарихы бай һәм дәвамлы процесс дип әйтеп булмый. Сөйләм теленең төрле аспектлары В. А. Богородицкий [Богородицкий], М. З. Зәкиев [Зәкиев], В. Х. Хаков [Хаков], Ф. С. Сафиуллина [Сафиуллина], И. М. Низамов [Низамов, 2002], [Низамов, 2006], Г. Р. Галиуллина [Галиуллина, Мубаракзянова, 2014], [Галиуллина], Д. К. Вахитова [2013], Н. Ф. Галиева [Galieva, Galiullina], [Галиева, 2016] хезмәтләрендә төрле дәрәҗәдә яктыртыла. Татар тел белеме фәнендә сөйләм теленең кулланылыш үзенчәлекләренә, әдәби тел нормаларына багышланган хезмәтләрләрдән сөйләм теленең аерым бер ярусын үзәккә алып, монографик планда эшләнгәнгәннәре күп түгел. Беренчеләрдән булып диярлек, бу мәсьәләне монографик планда эшләүгә Ф. С. Сафиуллина алынды. Аның бүгенге көндә дә гаять актуаль булуы, фәнни яктан югары дәрәҗәдә эшләнгәнлеге, сөйләм теле синтаксисына хас киң таралган үзенчәлекләрне һәм нечкәлекләрне тирәнтен анализлавы белән аерылып торган «Синтаксис татарской разговорной речи» [Сафиуллина] хезмәтен атарга кирәк. Шулай ук 2016 елда дөнья күргән «Татар лексикологиясе» [Татар лексикологиясе] академик басмасында да татар сөйләм теленең төп үзенчәлекләре һәм төрләре, кулланылышы турында мәгълүмат чагылыш тапкан.

Татар теле белемендә сөйләм телен, башлыча, функциональ стильләр күзлегеннән, матур әдәбият үрнәкләренә таянып яки вакытлы матбугатта кулланылышына нигезләнеп тикшерү таралыш тапкан. Сөйләм телен бу аспектларда өйрәнү аның табигатен, төп үзенчәлекләрен күзалларга ярдәм итсә дә, асылын тулысынча аңлауда кыенлыклар тудыра. Матур әдәбият әсәрләрендә, матбугат битләрендә урын алган сөйләм теле үрнәкләре билгеле бер дәрәҗәдә эшкәртелгән, кодификацияләнгән тел кануннарына яраклаштырылган була. Ә инде көндәлек аралашудагы сөйләм теленең тел ярусларының төрле катламнарына караган, нормалашкан телдә очрамый торган күренешләре игътибар үзәгеннән читтә кала.

Шундый үзенчәлекләрнең бер төркеме лексик интерференция күренеше нәтиҗәләренә карый.

Тел белемендә интерференция термины XX гасырның 40–50 нче елларында барлыкка килә һәм Уриэль Вайнрайхның «Languages in Contact: Findings and Problems» [Weinreich] хезмәтеннән соң киң таралыш таба. Татар тел белемендә бу мәсьәләгә караган фикерләр С. Г. Васильева [Васильева], Л. К. Бәйрәмова [Байрамова], Р. А. Юсупов [Юсупов], З. Ә. Исхакова [Исхакова, 2001], [Тюркские языки в условиях глобализации], Ф. К. Сәгъдиева [Сагдеева], Г. Р. Галиуллина, Д. Р. Мөбәрәкҗанова [Галиуллина, Мубаракзянова, 2013] һ. б. хезмәтләрендә урын ала.

Интерференция күренеше, нигездә, телара мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә туа һәм алар телләрнең эчке үсеш закончалыкларыннан бәйсез була. Шунлыктан, интерференциягә багышланган хезмәтләрдән күренгәнчә, бу очракта төп игътибар икетеллелек шартларында туган телнең икенче телгә тәэсирен өйрәнүгә юнәлтелә.

Интерференция күренешенә тәрҗемә теориясе кысаларында да аерым игътибар бирелә. Тәрҗемә процессында оригинал текстның кайбер элементларын тәрҗемә ителгән вариантына кирәксезгә күчерүне атау өчен әлеге термин кулланыла [Овчинникова, Павлова, б. 76].

Фәнни хезмәтләрдә бирелгән билгеләмәләргә күзәтү ясасак, интерференция күренешенә ике төп караш формалашкан. Аның беренчесе бер тел нормаларының икенче тел системасына тәэсире; бер телнең икенче телгә тәэсире нәтиҗәсендә тел структурасында һәм элементларында барган үзгәрешләр дип аңлату юнәлешендә булса, икенчесе исә бер тел нормаларының икенче тел тәэсирендә бозылуы буларак билгеле. Һәр ике юнәлеш тә интерференциянең телара бәйләнешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән хата икәнен инкяр итми. Әлеге фәнни карашлар интерференция күренешенә бирелгән билгеләмәдә дә чагылыш тапкан. Хәзерге тел белемендә аны ике төрле аңлату күзәтелә: киң мәгънәдә икетеллелек шартларында төрле телләр системасының үзара мөнәсәбәтен; билингваль шәхеснең сөйләмендә күзәтелә торган нормадан читләшү күренешен күрсәтсәләр, тар мәгънәдә исә билингваль шәхеснең туган теле тәэсирендә язма һәм сөйләмә телендә нормадан читләшүе очракларын атыйлар [Словарь социолингвистических терминов, б. 82].

Интерференция гаять дәрәҗәдә катлаулы һәм күпаспектлы күренеш санала. Хәзерге глобальләшү, телләр һәм мәдәниятләрнең үзара тыгыз бәйләнешы чорында бу күренеш күпчелек телләрдә күзәтелә. Шунлыктан аның табигатен, тәэсирен өйрәнү дә төрле юнәлешләрдә бара. Әлеге күренешне өйрәнүнең башлангыч чорларында туган телнең чит телгә тәэсире алгы планга чыкса, соңгы елларда исә кире интерференция күренешенә, ягъни җәмгыятьтә өстенлек алган чит телнең икетелле шәхеснең туган теленә тәэсире планында өйрәнүгә игътибар артты. Татар тел белемендә интерференция күренешенә багышланган хезмәтләрдә дә, башлыча, кире интерференция күренешен өйрәнү таралыш тапты.

Безнең әлеге мәкаләдә дә кире интерференция күренешенә басым ясала. Белгәнебезчә, структур яктан төрле булган телләрнең янәшә кулланылуы нәтиҗәсендә интерференция тел системасының барлык катламнарына да үтеп керә. Беренче чиратта, лингвистик интерференция сөйләм телендә барлыкка килә һәм таралыш таба. Шунлыктан бу күренешнең таралыш тизлеген, динамикасын һәм күләмен күзаллау туган телнең фонологик, грамматик һәм лексик системасында алга таба булырга мөмкин үзгәрешләрне, күчешләрне билгеләү максатыннан бик әһәмиятле.

Сөйләм телендә лексик интерференция иң киң һәм тиз арада таралыш тапкан күренеш санала. Беренчедән, кодификацияләнгән телнең башка катламнарына караганда, лексика экстралингвистик факторларга бәйле тиз үзгәрүчән, икенчедән, ул ачык система хасил итә һәм аның составы даими үзгәреп, тулыланып тора. Сөйләм телендә исә бу процесс тагын да активрак бара, шунлыктан башка тел һәм мәдәниятләрнең үзенчәлекләре бу өлкәгә аеруча тиз үтеп керә.

Телара бәйләнешләр нәтиҗәсендә аерым бер күренеш, предмет атамасы формасында урын алып, лексик системаның бер компоненты буларак яшәгән, татар теленең барлык катламнарында, стильләрендә иркен кулланыла торган алынма һәм калька сүзләр барлыкка килүе билгеле. Биредә без тел системасына кереп урнашкан һәм, башлыча, уңай бәяләнә торган бу төр лексикага аерым тукталмыйбыз. Безнең игътибар бүгенге билингваль татар кешесенең сөйләмендәге туган тел сүзләрен чит тел лексикасы белән алмаштыру үзенчәлек-

ләренә юнәлтелә. Алынма һәм калька сүзләрнең бер өлешеннән аермалы буларак, лексик интерференция телара сөйләм багланышларының тискәре формасы буларак күзаллана. Ул телнең эчке үсеш закончалыкларына йогынты ясый, чит тел элементының акрынлап телгә үтеп керү процессын, билингваль шәхеснең телләрне куллану күнекмәләренең үзгәрешен, тел кодларының үзара керешүен күрсәтә.

Бүгенге татар кешесе актив икетеллелек шартларында яши, аның сөйләм телендә татар һәм рус телләре үзара керешеп, гомуми лексик фонд хасил итә. Сөйләм процессында әлеге лексик состав, аңлы яки аңсыз рәвештә, чынбарлыкның аерым күренешләрен атау өчен, эмоциональ-экспрессив максаттан кулланыла башлый.

Сөйләм телендә рус теле берәмлекләре төрле өлкәләрдә һәм төрле күләмдә кулланыла. Биредә без, югарыда билгеләгәнчә, типик саналган, яшь һәм урта буын татарлар сөйләмендә очраган лексик берәмлекләрнең аерым төрләрен карыйбыз.

Шәһәрдә яшәүче татарлар телендә икетеллелек шартларында барлыкка килгән үзенчәлекләрне махсус өйрәнгән З. Ә. Исхакова татар сөйләменә рус теле берәмлекләренең килеп керүен «шәһәр җирлегендә яшәгән татарларның туган телне начар белүләре, сөйләм күнекмәләренең булмавы, туган телнең лексик байлыгына ия булмау һәм сөйләм төгәлсезлеге» нәтиҗәсе дип аңлата [Исхакова, 2001, б. 140]. Безнең күзәтүләрдән күренгәнчә, рус сүзләрен татар сөйләмендә куллану бүгенге көндә авыл җирлегендә яшәүче һәм туган теленең лексик байлыгын яхшы үзләштергән, татар телендә көндәлек аралашучылар сөйләмендә дә еш очрый.

Хәзерге татар сөйләм теленә хас интерференциянең сәбәпләре тирәндәрәк ята, ул лингвистик күнекмәләргә генә түгел, бәлки, психологик һәм социомәдәни шартларга турыдан-туры бәйләнгән.

Татар сөйләм телендә киң таралыш тапкан берәмлекләрнең функцияләренә һәм кулланылыш үзенчәлекләренә, таралыш киңлегенә игътибар итик.

Функциональ аспектта караганда, беренче чиратта, бу төр сүзләр атау, ягъни номинатив функция башкаралар. Актив билингваль шәхес туган телдә теге яки бу күренеш, предмет атамасы булмаганда яки аңлатма озын булганда, рус телендәге атаманы сөйләмгә әзер килеш ала, мәсәлән, *Алар белән беседкага мендек. Ел да шул гадәт бара* (47 яшьлек хатын-кыз респондент сөйләменнән), – *Үзеңнең заряднигың кая соң синең, әни? – Кызым, эштә онытып калдырганмын зарядныгымны* (20 һәм 52 яшьлек хатын-кыз респондентлар сөйләменнән); *Өйдә минем гитара бар, име, бер струнасы юк только* (25 яшьлек ир-ат сөйләменнән); *Сотовыеңны биреп тор әле, үземнеке өйдә калган* (18 яшьлек хатын-кыз респондент сөйләменнән); *Апайның давлениесе уйный әле бу арада* (48 яшьлек хатын-кыз респондент сөйләменнән) һ. б.

Татар сөйләм телендә исәнләшү, хуплау, килешү яки каршы килү функциясен башкара торган бер төркем лексик берәмлекләр очрый. З. Ә. Исхакова билгеләвенчә, «диалогларда рус сүзләре еш кына экспрессив характерда була һәм сөйләмне җанландыру максатыннан кулланыла. Аерым очракларда сөйләмдә кайбер берәмлекләрне файдалану теге яки бу төшенчәне төгәл, кыска формада бирергә ярдәм итә, дигән фикергә нигезләнә» [Исхакова, 2001, б. 142]. Автор бу төр сүзләрне «экспрессив характердагы чит тел сүзләре» дип билгели.

Хәзерге татар сөйләмендә рус телендәге исәнләшү, саубуллашу гыйбарәләрен куллану күзәтелә, мәсәлән, *привет*: *– Илзия, привет. – Сәлам, Ләйлүш. Бу елларда нишләдең?* (20, 22 яшьлек хатын-кыз респондентлар сөйләменнән); *пока, покалар: – Ярар ату, гадук белән чыгам инде, булмый бу. Синнән булмады. Ярар, покалар* (45 яшьлек ир-ат респондент сөйләменнән) һ. б. Шулай ук *ярар, пока; пока, иртәгәгә кадәр; покалар сезгә* кебек мисаллар да очрый. Тупланган материалны анализлау һәм тел корпусларына күзәтү ясау шуны күрсәтте: әлеге сүзләр, нигездә, сөйләм телендә актив, матур әдәбият әсәрләрендә сирәк очрый, публицистикада бөтенләй кулланылмый диярлек.

Татар сөйләм телендә соңгы берничә дистә елда рус сөйләм теленнән кергән *давай* сүзе (татар телендәге эквиваленты – *әйдә,* аерым очракларда семантик яктан *ярар* сүзенә туры килә) шактый активлашты. Модаль кисәкчә вазифасын үти торган әлеге сүз рус сөйләм телендә сөйләүченең ихтыярын, нindидер эш башкаруга өндәү мәгънәсен белдерә һәм аның функциясе шактый киң [Колесникова, б. 52].

Татар сөйләм телендә әлеге сүз саубуллашу формуласында да кулланыла, мәсәлән: *– Бәлки берәр чарасы табылыр. – Ооо, әйбәт булырие, давай***,** *иртәгәгә кадәр* (19, 20 яшьлек хатын-кыз респондентлар сөйләменнән). *– Ладно тогда, давай, киттем мин. – Ладно, алайса, давай* (32

һәм 50 яшьлек хатын-кыз респондентлар сөйләменнән). – *Ярый, давай, пока. – Ярый, рәхмәт* (23, 25 яшьлек хатын-кыз һәм ир-ат респондентлар сөйләменнән). Сөйләм телендә түбәндәге конструкцияләрнең киң таралышы күзгә ташлана: *давай, пока!; давай, иртәгәгә кадәр*; *давай, кергәләп тор; давай, күрешкәнче!; давай, сау бул; давайте, сау булыгыз* һ. б.

Татар сөйләм теленең диалогик формасында *давай* сүзенең өндәү, көчәйтү мәгънәсендә таралыш тапканлыгын да билгеләргә кирәк: – *Давай, иртәгә киноga барабыз; – Ярар, алайса, киттем мин. – Давай; – Хоккейга бару – минем бер хыял ул, дустым. Минем әле бер тапкыр да барган юк. Алла боерса, барырга кирәк. – Давай-давай, яңа сезон башлангач, Алла боерса, барырбыз; – Мин сиңа юл уңаеннан кереп чыгармын әле. – Әйбәт булырие <булыр иде>, давай* һ. б.

Матур әдәбият әсәрләрендә персонаж сөйләмендә әлеге берәмлек шактый киң функциядә кулланыла. Мисал өчен, әдәби әсәрләрне, фәнни хезмәтләрне, периодик басмаларны һ.б. язма чыганакларны үз эченә алган «Татар теленең язма корпусы»нда *давай* сүзе 572 тапкыр очрый: *Давай сөйлә, дим* (Р. Гаязетдин); *Давай, кунак булсаң, тыйнак бул* (Аманулла); *Сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәдем: «Син, давай, безгә сыпырт, барыбыз да монда», – дидем* («Татарстан яшьләре» газетасы); *Син, давай, икенче болай кеше көлдермә инде яме* («Безнең гәҗит» газетасы).

«Татар матур әдәбияты корпусы»нда әлеге сүз 283 тапкыр теркәлгән: *Давай, туп-туры икенче катка гына меник әле, ә? – дип, эскалатор ягына ымлады* (А. Әхмәтгалиева); *«Даваегыз, давай, күбрәк төягез!» – дип, бу эшкә Хафиз карт үзе җитәкчелек итеп торды* (В. Нуруллин); *Давай, шаяруларны куеп торыйк та конкрет эшкә килик: мин хәзер машина җибәрәм* (В. Имамов); *Давай, мастер, рычагларга баса-баса, Бөтен дөнья шаккатырлык рекорд яса!* (Г. Афзал); *Давай, агай-эне, бармакларың кыймылдаганда, ичмасам, бер әйттереп кал әле!* (Г. Бәширов) һ. б.

Хәзерге татар сөйләмендә *вот* (фонетик варианты – *вәт;* татар телендәге эквиваленты – *менә*) сүзе киң таралыш тапкан. Рус сөйләм телендә әлеге кисәкчә акцентлаштыру, килешү, көчәйтү, бәяләү, ироник мөнәсәбәт кебек мәгънәләргә ия [Колесникова, б. 55]. Татар сөйләмендә төрле ситуацияләрдә бу мәгънәләрнең зур күпчелеге чагылыш тапса да, инде калыплашкан, сөйләм телендә урнашкан мәгънәләрдән килешү, көчәйтү, раслау, акцентлаштыруны билгеләр идек: – *Вот хоккейга барып кара син, вот анда уйныйлааар... – Вот анда шуның хәтле эмоцияләр, беләсеңме?; Вот шул кыз булышты да инде; Вәт, шуның белән шул; Вәт малай, тәки үзенекен эшләде бит, ә! Вәт син миңа әйт әле, бу яңгыр туктыймы, юкмы?* һ. б.

Әйтергә кирәк, әлеге лексик берәмлек, сөйләм теле кысасында гына калмыйча, матур әдәбият әсәрләрендә дә персонажларның сөйләм үзенчәлекләрен күрсәтү максатыннан шактый иркен кулланыла. Мисал өчен, «Татар матур әдәбияты корпусы»нда *вәт* фонетик варианты 241 тапкыр, ә *вот* варианты исә 150 тапкыр кабатлана, мәсәлән, *Вәт әкәмәт, вәт әкәмәт, – дип сөйләнә-сөйләнә, Хөршидәттәй тәрәзә төбеннән күзлеген алып киде.* (А. Тимергалин); *Вәт сипкелле шайтан, никләр генә бәхәсләштем шуның белән!* (А. Гыймадиев); *Вәт баш бу Гөлүсәдә!* (А. Әхмәтгалиева); *Менә, вәт, күрдеңме инде!* (В. Нуруллин); *Якыннан алтынны, вот честно говорю, күргәнем юк.* (А. Гадел)*; Вот хәзер күрсәтә сезгә абзагыз үзенең нindирәк ковбой икәнен!* (В. Имамов); *Аларга хуҗа бар, бай инвесторга тәгаенләдем мин җирләрне, вот!* (Н. Гыйматдинова). Югарыда аталган кисәкчәнең һәр ике варианты кулланылышы хәзерге татар әдәбияты үрнәкләренә хас күренеш икәнен искәртү зарур.

«Татар теленең язма корпусы»нда мондый төр кабатланулар тагын да күләмлерәк: *вәт* фонетик варианты биредә 698, *вот* исә 449 контекстта очрый. Бу, үз чиратында, әлеге кисәкчәнең көндәлек аралашу телендә генә түгел, телнең башка катламнарына да үтеп, эмоциональ-экспрессив фон тудыру максатыннан кулланылуын күрсәтә.

Татар телендә *ну* сүзе шактый озак вакытлар кулланыла, һәм, алда каралган лексик берәмлекләрдән аермалы буларак, ул сүзлекләрдә урын алган. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә аның ымлык булуы һәм сөйләм теленә хас берәмлек икәнлеге, нәрсәне дә булса эшли башларга өндәүне; шаккату, гаҗәпләнү яки ризасызлык, канәгатьсезлек, ирония хисе; сорау җөмләнең башында килеп, берәр эшхәлдән соң нинди эш башкару турында сорауны; сөйли башлауны яки йомгаклауны белдерүе күрсәтелә [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 388]. «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә рус теленнән кергәнлеге билгеләнгән һәм ике мәгънәсе теркәлгән: «ну I

– но (союз) < рус; ну II – ну < рус» [Әхмәтьянов, б. 70]. Бу берәмлек татар телендә инде урнашкан, телнең төрле катламнарында һәм стильләрендә кулланыла дияргә кирәк. Тел корпусларындагы материаллардан күренгәнчә, *ну*, нигездә, ымлык буларак, «Татар матур әдәбияты корпусы»нда – 1220, «Татар теленең язма корпусы»нда 2741 очракта теркәлгән.

*Ну* сүзенең рус телендәге теркәгеч вазифасында кулланылышы очрамый диярлек, әмма «Татар матур әдәбияты корпусы»нда 81 мисалда әлеге мәгънәдә теркәлгән. Аларның күбесе матур әдәбият текстында бирелгән рус җөмләләре, репликалары составында килә, мәсәлән, *Но, но, а ну вас.* (Г. Каюмов); *«Странно, но мило!» – дип уйлап куйды ул эченнән генә һәм шуларның барысына да сокланып, йомшак урыныннан кузгалырга иренеп, озак кына карап ятты* (Ә. Еники) һ. б.

Болардан тыш, каршы куючы теркәгеч мәгънәсендә берничә мисал урын алган: *Ыслушай, Гомәр дус, дип сүз башлады Марат, теләсәң әләклә, теләмәсәң – юк, но без кәрт сугарга киттек!* (А. Гыймадиев); *Но чигенә белергә кирәк* (М. Мәһдиев); *Тануын танымйм, но җибәрә алмыйм* (М. Мәһдиев); *Минем сиңа шактый бирәчәгем бар шикелле, но анысын акрынлап түләрмен* (Ә. Еники); *Кадерле әти һәм әни, сеңлем Зөлхәбирә, сезгә ерак җирләрдә нахак бәла аркасында ятучы, но да ләкин, бер дә газап күрмичә, прораб булып акча эшләп ятучы улыгыз Зәкәрҗан күп сәлам җибәрә* (М. Мәһдиев) һ. б. Соңгы мисалга игътибар итсәк, татар сөйләм теле үрнәкләрен сәнгати югарылыкка күтәреп, әдәби әсәр тукымасының алыштыргысыз җәүһәрләре сыйфатында сурәтли белгән күренекле язучы М. Мәһдиев рус һәм татар телендәге каршы куючы теркәгечләрне янәшә куллана, шул рәвешле әсәрнең поэтикасын, тәэсир көчен тагын да арттыра.

Хәзерге сөйләм телендә әлеге сүзнең ике мәгънәсе дә актив, шулай ук урта буын вәкилләре сөйләмендә *ну* вариантында каршы куючы теркәгеч буларак та кулланылышы күзгә ташлана. Мисал өчен, түбәндәге диалоглардан өзекләргә тукталыйк: *Ну как, тегесен нишләттеләр? Ничә айга алып киттеләр?* (31 һәм 40 яшьлек ир-ат респондентлар сөйләменнән); *– Әйдә бүген, кич белән, баскетбол уйнарга чыгабыз! – Анда салкынмы соң? – Ну, яңгыр яуган* (20 яшьлек студент кызлар сөйләменнән); *Ну как, информатикаңны эшләдеңме, Айнур?; Безгә сугыш ветераннары турында мәгълүмат әзерлисе иде, но мин башканы сайладым* (20 яшьлек студент кызлар сөйләменнән); *– Ну, әгәр беркем дә булмаса инде, бәлки дәрестән бераз иртәрәк сорап китәрбез. – Но сорасак була инде, бер ун минутка сорасак, без поездга өлгерергә тиеш* (19–22 яшьлек студент кызлар сөйләменнән); *Без клубка бик чыкмыйдырыйык, ну, Мишә буена төшә торганыйык* (52 яшьлек хатын-кыз респондент сөйләменнән) һ. б.

Мондый төр лексик берәмлекләргә мисалларны күпләп китерергә була. Югарыда каралган сүзләрнең татар телендә эквивалентлары булуга карамастан, сөйләмдә рус вариантлары еш кулланыла. Аларның функциональ яктан активлыгын туган телне начар белү яки татар телендә аларны алыштырырлык кыска, семантик яктан тулысынча тәңгәл килә торган сүз булмауга яки ситуатив кулланылышка кайтарып калдырып булмый. Безнең анализда каралган очраклар бу шартларга туры килми, киресенчә, лексик интерференциянең системалы, татар телендә сөйләшүчеләр өчен гадәти күренеш икәнен, билингваль шартларда ике тел лексикасын янәшә куллануда чикләр җуела баруын дәлилли. Безнең фикеребезчә, татар-рус икетеллелеге даирәсендә лексик интерференция бер үк вакытта телләрнең үзара керешүенең, әдәби тел нормаларының үзгәрүенең һәм сөйләмгә хас хаталарның күрсәткече булып тора.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, югарыда каралган кире лексик интерференция күренеше татар телендә яшәп килгән эквивалентларның пассивлашып, алга таба сүзлек составыннан югалуына китерергә мөмкин. Сөйләм телендә барлыкка килгән мондый күренешләр соңрак әдәби телгә үтеп кереп, аның эчке төзелешенә тәэсир итәчәк.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. I том: А–Л. 543 б. Т. 2: М–Я. 567 б.

*Зәкиев М. З.* Төрки-татар этногенезы. М.: ИНСАН, РФК, 1998. 624 б.

*Низамов И. М.* Татар социолингвистикасы. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2006. 150 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М. З. Зәкиев; ред. Г. Р. Галиуллина. Казан: ТӘҺСИ, 2016. Т. II. 392 б.

Татар матур әдәбияты корпусы. URL: http://litcorpus.antat.ru/index_tt.htm (мөрәҗәгать итү көне: 17.03.2018).

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш ред. проф. Ф. Ә. Ганиев. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең язма корпусы. URL: http://www.corpus.tatar/tt (мөрәҗәгать итү көне: 17.03.2018).

*Хаков В. Х.* Татар әдәби теле: стилистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 302 б.

*Юсупов Р. А.* Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 287 б.

*Байрамова Л. К.* Татарстан: языковая симметрия и асимметрия. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. 267 с.

*Богородицкий В. А.* Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. Казань: Татгосиздат, 1933. 156 с.

*Васильева С. Г.* Разноязычие (смешанная речь) и типология билингвизма личности: дис. ... докт. филол. наук.: М., 2000. 351 с.

*Вахитова Д. К.* Инвективная лексика татарского языка: функциональный и этноментальный аспекты: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2013. 239 с.

*Галиева Н. Ф.* Языковые способы выражения эмоциональности в современной татарской прозе: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2016. 285 с.

*Галиуллина Г. Р.* О некоторых лексических особенностях татарской разговорной речи // И. А. Бодуэн де Куртенэ и мировая лингвистика: междунар. конф.: VI Бодуэновские чтения (Казан. федер. ун-т, 18–21 окт. 2017 г.): тр. и матер.: в 2 т. / под общ. ред. К. Р. Галиуллина, Е. А. Горобец, Д. А. Мартьянова, Г. А. Николаева. Казань: изд-во Казан. ун-та, 2017. Т. 1. С. 50–52.

*Галиуллина Г. Р., Мубаракзянова Д. Р.* Интерференция как один из факторов развития вариативности звуковой системы татарского языка // Филология и культура. Phililogy and Culture. № 3 (33). Казань, 2013. С. 59–61.

*Галиуллина Г. Р., Мубаракзянова Д. Р.* К вопросу разграничения терминов «разговорная речь» и «литературный язык» в современном татарском языкознании // Филология и культура. Phililogy and Culture. № 4 (38). 2014. С. 57-61.

*Исхакова З.А.* Двуязычие в городах Татарстана (1980–90-е годы). Казань: Фикер, 2001. 191 с.

*Колесникова С. М.* Русские частицы: семантика, грамматика, функции: монография. 3-е изд., стер. М.: Флинта, 2015. 112 с.

*Низамов И. М.* Татарская речь. Функционирование и развитие речевой системы в массовой коммуникации. Казань: Матбугат йорты, 2002. 271 с.

*Овчинникова И. Г., Павлова А. В.* Переводческий билингвизм: очерки по материалам ошибок письменного перевода. М.: ФЛИНТА, 2016. 304 с.

*Сагдеева Ф. К.* Проблемы культуры татарской речи в условиях активного двуязычия. Казань: Фикер, 2002. 128 с.

*Сафиуллина Ф. С.* Синтаксис татарской разговорной речи. Казань: изд-во Казан. ун-та, 1978. 253 с.

Словарь социолингвистических терминов / Под ред. В. Ю. Михальченко. М.: Институт языкознания РАН, Институт иностранных языков, 2006. 312 с.

Тюркские языки в условиях глобализации: (этносоциологический анализ татарского языка) / сост. Г. Ф. Габдрахманова, З. А. Исхакова, Р. Н. Мусина. Астана: Кантана-пресс, 2011. 394 с.

*Galieva N. F., Galiullina G. R.* Emotive idioms Tatar language as national mentality reflection // Journal of Language and Literature. Volume 6, Issue 1, 1 February 2015, Pages 273–276.

*Weinreich Uriel.* Languages in contact: findings and problems. New York: Linguistic Circle, 1953. 148 p.

---

# ЛЕКСИЧЕСКАЯ ИНТЕРФЕРЕНЦИЯ В СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ РАЗГОВОРНОЙ РЕЧИ

**Гульшат Раисовна Галиуллина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
Gulshat.Galiullina@ksu.ru.

Статья посвящена изучению лексической интерференции в современной татарской разговорной речи. Основное внимание уделяется функциональным особенностям интерферентных явлений и степени их распространения в разговорной речи. Фактическим материалом исследования послужили 120 аудиозаписей неподготовленной, спонтанной речи татар разной возрастной группы и социального статуса. Также для подтверждения отдельных выводов привлечены материалы «Письменного корпуса татарского языка» и «Корпуса татарской художественной литературы».

В результате анализа выявлено, что лексическая интерференция, наблюдаемая в современной татарской разговорной речи, зависит не только от лингвистических факторов. Она напрямую связана с психологическими и социокультурнымы факторами. Несмотря на то, что в татарском языке существуют эквиваленты, употребление слов чужого языка носит системный характер, для носителей татарского языка включение этих слов в речь является привычным яв-

лением. Это, в свою очередь, является показателем размытости границ между двуми языками в активной билингвальной среде.

**Ключевые слова:** татарский язык, разговорная речь, билингвизм, интерференция, лексика, лексическая интерференция.

Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта № 17-14-16012.